Яшь ветеринарлар йортлы булды

Кече Елга авылының Тынычлык урамында үзенчәлекле ветеринария үзәге пәйда булды. Маллар дәвалаучы участок табибы пунктыннан тыш, биредә әле яңа торак йорт та салып куйганнар. Анда мал табибы булып эшләүче Айгөл белән Илнур Нәбиуллиннар гаиләсе яши.

7 БИТ

Нәтиҗәдә, нәрсә бар – шул бар

Республиканың 507 авылында кибетләр бөтенләй юк. Биредә автолавкалар белән хезмәт күрсәтәләр. Мондый машиналарның саны 100гә якын. Әшне тиешле дәрәҗәдә оештыру өчен, янадан 57 машина кирәк. 2016 елдан «Авыл кибете» максатчан программасына старт биреләчәк. Әлеге проект нигезендә, Татарстан авылларында модульле кибетләр барлыкка киләчәк.

3 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри КАЗАН

татмедиа

Сишәмбе | 31.01.2017 | №9 (5771)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

ӘЙЛӘНӘ МАШИНА ӘЙЛӘНӘ

Левченко бистәсенең Рәхимов урамында республикада бердәнбер карусель-парковка урнашкан. Гадәти булмаган әлеге машина кую урыны ун автомобильгә исәпләнгән. Редакциянең машина йөртүчесе Альберт Каюмов белән парковканың отышлы һәм уңайсыз якларын без дә сынап карадык.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Алдан ук әйтик, әлегә бу проект шәһәр хакимиятендә яклау тапмаган. Аны офислары шунда урнашкан бер шәхси ширкәт хезмәткәрләре ясаган. Чит илләрдә, Россиянең кайбер шәһәрләрендә мондый машина кую урыннары популяр, ди. Ишегаллары машина белән тулы Казанда да аңа ихтыяҗ булыр дип уйлаганнар.

– Гадәттә, кайбер ишегалларында бер машина куярга да урын таба алмыйсың. Шәхси оешмалар өчен дә хезмәткәрләрнең машиналарын куеп торырга уңайлы парковка булыр иде, – ди компаниянең персонал буенча менеджеры Максим Игумов.

Ни өчен карусель? Чөнки ул әйләнә, исеме дә эшләү механизмыннан алынган. Карап торышка киштәле этажерканы хәтерләтә. Һәр киштә – машина кую урыны. Җайланманың төймәсенә басып, үзеңә кирәкле буш киштәне төшерәсең. Аннары машина шунда кереп урнаша. Йөртүче машинасын бикли дә тагын шул төймәгә баса – машина өскә күтәрелә. Редакция машинасының таган кебек якка чайкалып менгәнен күргәч, башта куркып ук куйдым, килеп төшәр сыман тоелды. «Куркынычсызлыкка килгәндә, бер дә борчылыр нәрсә юк», – дип ышандыра Максим.

– Көн саен диярлек машинамны шул парковкага куям. Үзебездә зур чаралар узганда, кунакларның машиналарын кую өчен дә уңайлы. Чыдамлы да: инде икенче кыш эшли, әлегә бер дә ватылмады. Без аны салкыннарга чыдам материаллар кулланып төзедек, – ди аңгәмәдәшем.

Баштарак бу идея белән шәһәр хакимияте дә, башка оешмалар да кызыксынганнар. Парковкалар проблемасын хәл итү өчен чынлап та отышлы җайланма кебек бит. Тик аны кибет территорияләренә, шәһәр үзәгенә урнаштыру тәкъдиме хупланмаган. Хәзер компаниянең ишегалдында урнашкан үрнәк буларак ясалган бу карусель-парковканы сатуга куйганнар. Торак милекчеләре ширкәтләренә дә тәкъдим итеп караганнар. Алучысы гына юк әлегә. Максим әйтүенчә, машина куя торган бер урын 450 мең сум тора. Парковка үзе 4 миллион 500 мең сумлык. Күпләр кыйммәтсенә. Өстәвенә, парковканы урнаштырганда билгеле бер кагыйдәләргә таянырга, әйтик, янгын куркынычсызлыгы идарәсенең таләпләре үтәлергә тиеш.

Эльвира МОЗАФФАР.

Сүзен-сүзгә

Зөлфәт ЗИННУРОВ, алып баручы, журналист:

– Парковка бүген иң ачу китергән нәрсә, зур проблема. Социаль ипотека буенча төзелгән йортларны гына алыйк. Мәсәлән, Глушко урамында машина түгел, бала арбасы белән йөрерлек урын да юк. Йортларны салганчы ук, машина кую урыннарын уйласыннар иде. Ниндидер шәхси компания үз тырышлыгы белән шундый гадәти булмаган парковка уйлап чыгарган икән, мин моны хуплыйм гына. Үземнең йорт белән торгач, безнең парковка проблемасы юк анысы. Шулай да шәһәр җирендә яшәсәм, ишегалдында шундый җайланма урнаштырсалар, ике дә уйламый, машинамны куяр идем. Урынны сатып алу кыйммәткә төшсә дә, көн саен машина кую урыны эзләп йөрү дә җиңел түгел бит. Аннары газоннарга, башка урыннарга машинаңны дөрес куймасаң, зур күләмдә штрафлар салына. Бу яктан да карусель-парковкалар үзен аклый кебек.

Альберт КАЮМОВ, машина йөртүче:

– Мин мондый карусель-парковканы беренче тапкыр Белоруссиядә күргән идем. Сатып алу өчен кыйммәтрәк анысы. Ә гомумән ошады. Уңайлы, күп урынны алмый. Шәһәр үзәгендә урнаштырылса, бигрәк тә отышлы булыр иде. Анда парковка табуы аеруча авыр бит. Тик мондый металл, зур конструкция шәһәр архитектурасын бозар, аннары янгын күзәтчелеге куйган таләпләренә дә җавап бирмидер, мөгаен.

Миләүшә ВАФИНА, газета укучыбыз:

– Минемчә, гади халык өчен 450 мең сум кыйммәт. Ул акчага гараж сатып алырга була. Машина ручника куелмыйча, таудан тәгәрәп киткән очраклар бар, бу парковкадан машиналар төшеп китә башласа нишләрсең? Ишегалдында балалар уйный, кеше йөри. Куркынычсызлык ягын уйлап бетерергә кирәк.

Казанда йортлар «яшелләнергә» җыена

Казанда узган ел «Современник» торак комплексында (Алексей Козин урамы, 5) BREEAM халыкара экология стандартлары сертификатына лаек булган күпфатирлы торак йорт файдалануга тапшырылды.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

– Башкалада халыкара «яшел стандарт»лы беренче йорт әле бу. Ул экологик чиста чималлардан төзелүе, энергия һәм табигать чыганакларын сакчыл куллануга көйләнелгәнлеге белән үзенчәлекле. Тагын ике төзелеш оешмасы халыкара экология стандартларын үз эшчәнлекләрендә кулланышка кертергә әзерләнә, – дип хәбәр итте шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Азат Нигъмәтҗанов «эшлекле дүшәмбе» киңәшмәсендә.

Узган ел Казанда 925 073 квадрат метр торак файдалануга тапшырылган. Күпфатирлы 85 йорт – коммерция инвестицияләре хисабына, ә күпкатлы тугыз йорт Дәүләт торак фонды программасы буенча сафка бастырылган.

– Торак төзелешләренең иң зур өлеше, ягъни 32,3 процент Совет һәм Идел буе районнарына туры килә. Авиатөзелеш һәм Мәскәү районнарында 2,9 процент кына. «Заречная» яңа торак комплексында төзелешләр башлау әлеге районнар җирлегендә дә төзелеш колачларын киңәйтәчәк. Шәхси торак төзелешләре күбрәк Казанның көнчыгыш тарафында – элек Биектау районына караган җирләрдә һәм шулай ук шәһәрнең Лаеш, Биектау, Яшел Үзән районнары белән чиктәш территорияләрдә алып барыла, – диде Азат Нигъмәтҗанов.

Быел 800 мең квадрат метр торак төзү ниятләнелә. Урман арьягы (Залесный) бистәсе янәшәсендәге «Салават күпере» комплексында төзелешләр дәвам итә. Беренче чираттагы күпфатирлы 22 йортның алтысы инде төзелде. Оренбург трактында социаль программа буенча төзелә торган 306 фатирлы йортны якын арада файдалануга тапшыру көтелә. М-14 микрорайонында 765 фатирлы өч йортны өченче квартал ахырына тәмамлау планлаштырылган.

«Весна» торак комплексында – «Унистрой», «Залесный Сити» торак комплексында – «Сувар Девелопмент» һәм «Садовое Кольцо» торак комплексында «Ак Таш» төзелеш оешмалары эш башкара. Быел «Весна» һәм «Станция «Спортивная» торак комплексларында ике балалар бакчасын, «Седьмое небо» һәм «Салават күпере» торак комплексларында 1224 урынга исәпләнелгән өч мәктәпне, Отары бистәсендә мәдәният йортын, Вознесенское бистәсендә табибларның гомуми практика офисын сафка бастыру билгеләнгән. Башкалада янә 15 спорт мәйданчыгы һәм модуль чаңгы базасы барлыкка киләчәк.

– Казанда соңгы ун елда 106 балалар бакчасы һәм мәктәп, 28 медицина учреждениесе файдалануга тапшырылды. Казанда 2035 елга торак белән тәэмин ителешне 31,1 квадрат метрга җиткерү бурыч итеп куелды, – дип, киләчәкне дә күзаллады Азат Нигъмәтҗанов. – Әлеге күрсәткеч Чехиядә – 29, Ирландиядә 35 квадрат метр.

Мэр Илсур Метшин, үзенең фикерләре белән уртаклашканда, төзелешне «лакмус» кәгазенә тиңләде.

– Башка шәһәрләрдә булганда, мин төзелеш краннарын күзлим. Төзелеш ул – лакмус кәгазе кебек. Башня краннары эшли икән, димәк, шәһәрдә тормыш һәм үсеш бар. Казанда төзелеш тармагында 72 мең кеше хезмәт куя, шәһәр һәрьяклап үсештә. Элек йортларның коры диварларына да риза була идек. Хәзер инде халыкара яшел стандартларга лаек йортлар төзергә, экологик чималлар куллануга омтылабыз, – диде Илсур Метшин.

Шәһәр башлыгы өлешле төзелештә янә четерекле мәсьәләләр килеп чыкканлыгын да телгә алды. «Свей» һәм «Маг-Строй» оешмалары төзи башлап, соңрак «сакаллы» корылма хәленә төшкән күпкатлы биш йорт тулысынча төзеп бетереләчәк.

Дамир БӘДРИЕВ.

1 февральдән эшләмәүче пенсионерларның иминият пенсияләре 5,4 процентка артачак, дип хәбәр итә Россия Пенсия фондының Татарстан бүлеге. Безнең республикада бу яңалык 800 меңләп пенсионерга кагылачак.

Пенсия арта

Эльвира МОЗАФФАР

Яңа система нигезендә, картлык буенча пенсия башлыча өч өлештән туплана. Фиксацияләнгән, ягъни бердәй түләү; туплануга өлеш һәм иминият пенсиясе. Фиксацияләнгән түләү бар кеше өчен дә бер үк. 2017 елда ул артып, 4805,11 сум булачак. Иминият пенсиясе исә кешенең пенсия баллары кушылмасына карап җыела. Әлеге балл яки шәхси пенсия коэффициенты моңа кадәр 74 сум 27 тиен булса, 1 февральдән 78 сум 28 тиенне тәшкил итәчәк.

Россия Пенсия фондының Татарстан бүлеге идарәчесе Эдуард Вафин әйтүенчә, картлык, инвалидлык буенча, шулай ук тәрбиячесен югалткан балалар өчен бирелә торган иминият пенсиясе дә эшләмәүче пенсионерларга 5,4 процентка артачак. Ә менә эшләүче пенсионерларга килгәндә, алар бу акчаларны, кагыйдә нигезендә, эштән китеп өч ай узгач алырга хокуклы.

Росстат мәгълүматлары буенча, 2016 елда инфляция 5,4 процентны тәшкил иткән, шуңа да пенсия дә нәкъ шул күләмдә арткан.

Пенсионерлар өчен апрель тагын күчтәнәч әзерли. 1 апрельдән социаль пенсияләр артачак. Августта исә, гадәттәгечә, эшләүче пенсионерларның акчаларын кире исәпләячәкләр, индексация нәтиҗәсендә кайберәүләрнең пенсияләре сизелерлек артырга мөмкин.

Пенсия өлкәсендәге үзгәрешләр турында газетабызның киләсе саннарында тулырак язарбыз. Әлеге темага карата кызыксындырган сорауларыгызны ***(843) 562-50-03, 8 (917) 851-69-62*** *телефоннары аша редакциягә юллый аласыз.*

«Банк эшчәнлеге контрольдә тотылырга тиеш»

«Банк эшчәнлеген ныклы контрольдә тотарга кирәк. «Татфондбанк» белән бәйле борчулы хәлләрдән соң физик затларны яклый алдык. Юридик затларны да якларга кирәк. Банкның үз акчасы юк, алар барысы да гади гражданнар, предприятие, оешма акчалары. Банк әлеге акчаларны әллә нинди аңлашылмый торган операцияләргә юнәлтә. Банк берике көндә генә банкротлыкка чыкмый. Милли банк аларны контрольдә тотарга тиеш. Әлеге мәсьәлә турында уйларга вакыт», – «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында VI чакырылыш Дәүләт Думасы депутаты Илдар Гыйльметдинов журналистлар белән очрашуда шулай дип белдерде. Матбугат очрашуында ул Дәүләт Думасының язгы сессиясендә каралачак кайбер башка өстенлекле закон проектлары белән дә таныштырды.

Россия Дәүләт Думасы депутатлары язгы сессиядә 131 закон проектын караячак. Әйтик, махсус икътисади зоналар турында закон беренче укылышта кабул ителгән, хәзерге вакытта Россия Икътисади үсеш министрлыгы белән ныклы эш алып барыла. Легаль булмаган алкоголь әйләнешенә каршы көрәш алып барырга ярдәм итә торган закон проекты эшләнә. Административ кодекска да үзгәрешләр эшләнә, алар контрафакт алкогольне җитештерү һәм сату өчен штрафларны үзгәртүгә юнәлдерелгән. Дәүләт Думасы юлда куркыныч тудырган өчен җәза турындагы закон проектын беренче укылышта кабул итте.

– Машина йөрткәндә куркыныч тудырган өчен, 5 мең сум штраф кертелә. Алдагы укылышларда, бәлки, штрафның күләме зуррак та булыр әле. Закон проекты юл хәрәкәте куркынычсызлыгы буенча Россия законы таләпләрен бозуга карата җаваплылыкны көчәйтү максатына юнәлдерелгән, – дип сөйләде Илдар Гыйльметдинов.

Быелның 1 мартында торакны бушлай хосусыйлаштыру срогы бетә. Әмма депутатлар кайбер категория кешеләр өчен алга таба да бушлай хосусыйлаштыру хокукын бирергә уйлый.

– Бу категориягә ятим балалар, кырымлылар, авария хәлендәге йортларда яшәүчеләр керер дип торабыз, – ди депутат.

Дәүләт хезмәткәрләре керемнәре турындагы мәгълүматны дөрес күрсәтмәгән очракта, төбәк җитәкчелеге аларга җәза бирү механизмын карый алачак – әлеге закон проекты беренче укылыштан узган.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА.

«Зур максатлар куеп эшләүче амбицияле җитәкчеләр юк, көндәлек тормыш белән генә яшисез, алдагы буыннар тарафыннан оештырылган база нигезендә көн күрәсез. Болай итеп үсеп булмый. Республиканың кулланучылар кооперациясенә йөкләнгән бурычларның мөһимлеген без яхшы аңлыйбыз. Сез җаваплылык тоярга тиеш. Яңа чорда бик күп кооперацияләр, башка юнәлештәге оешмалар кебек үк, базаларын да, кадрларын да югалтырга өлгерде. Нәтиҗәдә, нәрсә бар – шул бар», – диде премьер-министр урынбасары – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтов Татарстан кулланучылар берлеге коллегиясе утырышында.

Нәтиҗәдә, нәрсә бар – шул бар

gazeta.ru

Зөлфия ХӘЛИУЛЛИНА

АВЫЛГА КИБЕТ КИРӘК

2016 елда берлеккә бюджеттан 42 млн сум акча бүлеп бирелгән булган. Әмма ул акчаның 10,5 млн сумы файдаланылмаган. Министр моны булдыксызлыкның бер күрсәткече дип белдерде. Чыннан да, ярдәм итәбез дип торганда, нигә бу мөмкинлектән файдаланмаска? Кулланучылар берлеге, авыл җирлегендә яшәүчеләр өчен кирәк-яракларны сатудан тыш, дистә еллар буе халык өчен табыш китерә торган бер тармак та булды. Терлек тиреләре, йон, ит тапшырып, халык азмы-күпме керем ала торган иде. Бүгенге көндә сарык асраучылар, тирене, йонны чыгарып кына атабыз, дип сөйлиләр. Республиканың бары тик алты районында: Азнакай, Әлмәт, Чистай, Кукмара, Балык Бистәсе, Мамадышта йон җыеп эшкәртү урыннары бар. (Сүз уңаеннан шуны да әйтеп китик, сарык йонына бәяләр артачак.)

Моннан тыш, кооперативлар үсеше өчен төрле проектларны тормышка ашыруга Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында 200 млн сумнан артык акча каралган. Марат Әхмәтов тәкъдим ителгән барлык проектларны да өйрәнергә, нигезле булганда, аны тормышка ашыруда ярдәм итәргә әзер булуларын турында әйтте. Эшкәртү цехлары, яшелчәләрне саклау урыннарын тәртипкә китереп, шактый керем алып булуы турында да ассызыкланды. Бу өлкәдә зур планнар белән яшәүче, эшләүче районнарның берсе – Кукмара. Районда барлык кибетләргә диярлек ремонт ясалган, җитештерү цехлары ачканнар. Киләсе елда җиләк-җимеш һәм яшелчәләрне консервлау цехы ачарга исәплиләр.

Татарстан кулланучылар берлеге җитәкчесе Мәхмүт Фәттахов та үзенең чыгышында җитештерү тармакларын ныграк үстерергә кирәклеге турында әйтте. Үз товарыңны сатканда, әлбәттә, күбрәк табыш алырга була. Сүз дә юк, кулланучылар берлегенең төп максаты, әлбәттә, бик күп табыш алып булмаган, халык аз яшәүче авылларны азыктөлек, кирәк-яраклар белән тәэмин итү. Республиканың 507 авылында кибетләр бөтенләй юк. Биредә автолавкалар белән хезмәт күрсәтәләр. Мондый машиналарның саны 100гә якын. Эшне тиешле дәрәҗәдә оештыру өчен, яңадан 57 машина кирәк. 2016 елдан «Авыл кибете» максатчан программасына старт биреләчәк. Әлеге проект нигезендә, Татарстан авылларында модульле кибетләр барлыкка киләчәк. Проекттан күренгәнчә, төзеләчәк кибетләрнең иңе – 7, буе – 7,3, биеклеге – 3 метр. Иң беренче чиратта мондый модульле кибетләр 100 хуҗалыклы, әмма бернинди дә кибете булмаган авылларда төзеләчәк. Районнардан инде күпмедер заявка да җыелган, коллегиядә төгәл генә сан әйтелмәсә дә, аларның саны шактый җыела, ахры. Хәтта 120 хуҗалыклы авылларда кибет юк дигән мәгълүмат Марат Әхмәтовны да ышандырып җиткермәде бугай. Тулы, төгәл саннарны җыярга кирәк, диде. Икенче чиратта 60-70 хуҗалыклы авыллар тора.

«БАРЫП КАРАРГА УЙЛАП ТОРАМ»

Бүгенге көндә бөтенләй кибетсез яшәүне күз алдына китерү дә кыен. Зур шәһәрләрдә көн түгел, төннең теләсә кайсы вакытында да кибеткә кереп үз кирәгеңне алырга була. Авылларда бар да башкача, һәр җирлек үзенчә җайлашырга тырыша.

Ризаэлә Миңнеханова Мамадыш районыннан, кече авылларның тормышы аңа бик яхшы таныш.

– 36 ел сәүдә тармагында эшлим. Бүгенге көндә үзебезнең җиде кибетебез, бер икмәк пешерү цехыбыз бар. Үзебезнең кибетләрне бер кат рәтләп бетергәч, кечкенә генә өч авылга барам. Аның керемен-чыгымын уйлап торган юк инде. Эш булсын, каядыр барасы гына булсын. Әллә нәрсә сатып алган кеше юк ул авылларда, хәзер бөтен кешедә диабет. Шуңа күрә бар да кара ипи ала, әллә нигә бер печенье-фәлән, атнага бер тапкыр берәр баллы ризык алалар. Иң күп сатылган ризык – тавык ите, казылык. Әле менә телевизордан Балык Бистәсе районының Ырга авылын күрсәттеләр, кибетләре юк икән. Бездән 90 чакрым, барып карарга исәп. Сатып алучы булгач, нигә аларны тилмертергә? – ди Ризаэлә ханым.

Аның белән сөйләшкәч, Балык Бистәсенең Ырга авылы белән дә элемтәгә чыктык. Әңгәмәдәшем үзенең исем-фамилиясен күрсәтмәвебезне сорады.

– Йорт исәбен әйтсәм ялгышырмын, безнең авылда якынча 130 кеше яши. Кибет юк, автолавкалар да килми, атнага өч тапкыр ипи китереп саталар. Алучысына да, сатучысына да бер газап инде ул. Өлкәннәр сигез тулганчы урамга чыгып басалар. Шушы салкында урамда тор инде син. Кайсы көнне иртә килә, икенче көнне соңга кала, юл гел бер төсле булмый бит инде ул. Казанга эремчек сатарга баручылар үз кирәкләрен шуннан алып кайта, кем районнан ала. Инде беркая да бара алмаган кешеләргә шикәр, тоз, он, май ише әйберләрне ипи машинасының шоферы алып килә. Ул үзе үк сата да инде, – диде ул.

«Авыл кибете» программасы тормышка ашса, кечкенә авылларда яшәүче өлкәннәребезгә дә йомшак икмәк ашарга насыйп булыр, Алла боерса.

«Ул миңа сеңлем кебек иде»

27 гыйнвар көнне 44 яшендә танылган Россия футболчысы, УЕФА Кубогы финалисты Татьяна Репейкина арабыздан китеп барды. Кайбер мәгълүмат чараларында аны, грипптан соң өзлегеп үлде, дип яздылар. Без исә Татьяна турында үзен аның апасы дип йөрткән якын дусты Гөлнара Юнисовадан сораштык.

vk.com

Татьяныны күпләр 1990 елларда «Гамма-ТАН» Казан командасында уйнаган вакытыннан белә. Соңрак ул Украинаның «Борисфен», «Динамо», Тольяттиның «Лада» командасы составында уйный. Пермьнең «Звезда-2005» төркеме составында чагында, өч тапкыр Россия чемпионы исемен ала, Россия Кубогына ия була.

Татьяна Репейкина бер ел элек спорттан китәргә карар кылган. Спорт мастеры дәрәҗәсенә ирешкән якташыбыз Казанда балаларны футбол уйнау серләренә өйрәткән, «Мирас» спорт мәктәбендә спорт буенча дәресләр алып барган.

Гөлнара Татьянаны кечкенәдән белә. Алар икесе дә Лаешта балалар йортында тәрбияләнгәннәр. Шуннан бирле аерылмас якын дуслар.

– Таняның температурасы югары булды, ул салкын тиеп авырды. Грипп булдымы, кискен тын юллары вируслы инфекциясеме – төгәл генә әйтә алмыйм. Ул хастаханәгә бармады. Авыруны аяк өстендә уздырды. Гриппка каршы прививка да ясатмаган иде. Шулай күпмедер йөргәннән соң, хәле бөтенләй начарланды. Мин куркып, ашыгыч ярдәм хезмәте чакырттым. Аны хастаханәгә алып киттеләр. Татьяна бер атна реанимациядә ятты. Ике яклап үпкәсе ялкынсынган иде. Кызганыч, авыруны җиңә алмыйча, дустым арабыздан китеп барды, – диде Гөлнара Юнисова «ШК»га.

Татьянага патологик анатомия бүлегеннән бирелгән белешмәдә дә үлеменең сәбәбен «ике яклап үпкә ялкынсынуы» (двусторонняя пневмония) дип язганнар.

Татьяна Репейкинаны Лаешта җирләделәр.

– Соңгы юлга озатканда ярдәм күрсәткән барлык кешеләргә, шулай ук командада бергә уйнаган иптәш кызларына зур рәхмәт белдерәсем килә, сеңлемнең урыны җәннәттә булсын, – ди Гөлнара.

PS. Татарстанның Роспотребнадзор идарәсе матбугат үзәге хәбәр итүенчә, эпидемия сезоны башланганнан бирле, Татарстанда 242 грипп очрагы теркәлгән.

ТАТАРСТАННЫҢ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ КИСӘТӘ

Авыруның беренче билгеләрендә үк 24 сәгать эчендә вируска каршы препаратлар, дарулар кулланырга, С витаминына бай ризыклар ашарга киңәш ителә. Мөстәкыйль дәваланырга ярамый. Авырып китсәгез, өйдә калыгыз. Вакытында дәваланмаган очракта, грипп пневмония, борын куышлыгы ялкынсынуы, нерв белән бәйле авыруларга китерергә мөмкин.

Әгәр янәшәңдәгеләр авырыйлар икән, маска киеп йөрсәң, ышанычлырак. Борынны тозлы су белән юдыруны гадәткә кертергә кирәк.

Онытмагыз: гриппны аяк өстендә үткәрергә ярамый.

Тегүче егет чемпионатка әзерләнә

17 яшьлек Рәмзил Камалиев – тегүче. Хәзерге вакытта ул технология һәм дизайн көллиятенең III курсында укый. Укытучылары канәгать егеттән. Ул курсташ кызларын шаккатырып, башка сыймаслык кием модельләре уйлап табарга сәләтле. Шуңа да Рәмзилне «WorldSkills» эшче һөнәрләр чемпионатының «Яшь профессионаллар» дигән төбәк бүлегенә тәкъдим иткәннәр.

«WORLDSKILLS» КӨНДӘЛЕГЕ

Алисә САБИРОВА

– Башта дуслар да, әти-әни дә сайлаган һөнәремне аңламады. Янәсе, ир-ат эше түгел бу. Ләкин мин кечкенәдән рәсем ясарга, төрле кием модельләре уйлап табарга яраттым. Ике сеңлем бар, аларның курчакларына киемнәр тегеп бирә идем. Рәсем конкурсларында катнашып, көчемне сынадым, – ди егет.

Рәмзил Кукмара районы, Туймаш авылында туып-үсә. Мәктәпне тәмамлагач, авылдаш кызы киңәше буенча, көллияткә укырга керә. Биредә күннән төрле әйберләр ясый. Шуңа өстәп, үзлегеннән тукымадан киемнәр тегәргә өйрәнә.

– Интернеттан карап, төрле китаплар укып чиләнеп беттем. Барыбер барысына үч итеп өйрәндем бу эшкә. Хәзер үземә дә, сеңелләремә дә кием-салымны үзем генә тегәм, – ди Рәмзил.

Быел 1-2 февраль көнне булачак чемпионатта ул өч көн эчендә биш төрле сынау узачак. Жакет, күлмәк тегүдән тыш, Рәмзил әле киемне бизәргә, макетын әзерләргә, эскизын ясарга тиеш.

– Жакет тегү өчен – 9 сәгать, күлмәккә 6 сәгать вакыт бирәләр. Хәзер тиз һәм сыйфатлы эшләү өчен кул шомартам. Иң мөһиме – каушамаска. Каушасаң, нинди тәҗрибәле белгеч булсаң да, коелып төшәсең. Көндәшләремә дә карамаска тырышам, югыйсә, аларныкы матуррак чыга, дип борчыла башлыйм. Бу бәйге белән генә тукталып калырга җыенмыйм, – ди яшь тегүче.

Автор фотосы

Көллиятнең исә зур җиңүләргә мөмкинлеге бар. Былтыр студентлары Диана Гайнетдинова, Минск шәһәрендә узган «WorldSkills»ның милли чемпионатында Кытай, Корея, Казахстан, Белоруссиядән килгән көндәшләрен узып, өченче урын алган. Хәзер ул башка студентларны әзерли.

Мода технологиясе дигән белгечлек буенча республика этабында барлыгы сигез кеше көч сынашачак. Яшь белгечләрнең эш дәрәҗәсен «WorldSkills» чемпионатының Татарстан Республикасы буенча «Мода технологиясе» компетенциясенең баш эксперты Ирина Купряхина күзәтә.

– Әле безгә үсәргә дә үсәргә. Заманча техника булмау – төп кимчелегебезнең берсе. Тегә торган машиналарны гына алыйк. «WorldSkills» стандартлары буенча, аларның куллану вакыты өч елдан да артык булмаска тиеш. Европа стандартлары буенча уку-укыту программасы белән тәэмин ителеш юк. Без әлегә дөнья дәрәҗәсенә чыга алмыйбыз. Россия җыелма командасы, бу компетенция буенча гомумән әлегә бөтендөнья ярышларында катнашмый, – диде Ирина Купряхина. Тик ул әлеге чемпионатның уңай яклары күп булуы бәхәссез икәнлеген дә ассызыклый: – Хәзерге вакытта уку йортларын тәмамлаган студентлар беренче көннән үк эшкә тотына алмый. Эшкә килгәч тә, без әле аларны яңадан өйрәтергә мәҗбүр. Ул да бит күп вакытны ала. «WorldSkills» чемпионаты бу кимчелекләрне бетерер дип ышанам.

Хатыннар заманасы

25 яше тулып килүче бер таныш кыз зарлана: «Кияүгә чыгарга вакыт җиткәнен дә беләм, тик кемгә? Бер-ике тапкыр очрашып алырга теләгән егетләр күп, тик менә кияүгә алам дигәне юк бит!» 21е тулырга маташучы икенче кыз: «Юк, егет тә юк, очрашкан да юк. Тагын бер-ике ел көтәм дә үземә иптәшкә бәбәй табам да үстерәм. Эшем бар, торыр урыным бар...» – ди.

30ы тулып килүче яки тулып киткән бернича туташтан әзрәк башкачарак сүзләр: «Ичмасам, берәр нормальный ир очраса, бәби табып булса да каласы иде», – дигәнне ишетәм.

Егетләр юк, ирләр юк дисерсең. Ә бит болай караганда, бар кебек алар.

Эчкечелектән дәвалый, дөресрәге, «запойдагы»ларны айныта торган клиника. 45ләп ир-ат ята. Күбесе –30-35 яшьлекләр. Болар инде бернича тапкыр кодлаштырылган, айныгра, тормыш корырга уйламаучылар. Эш кайгысы да, гаилә кайгысы да юк боларда...

...Наркоманнарны дәвалый торган үзәк. Алтмышлап кеше ята, күбесе – 22-30 яшьлек егетләр. Болар – ныгытып наркотик кулланучылар, ни аяныч, тик әйтми булмый: болар инде кеше була алмаячак. Чаллыда яшәүче бер туташ кияүгә чыкты. Ире матур сөйли, киенә, каядыр эшләп тә йөри. Өч айдан ир «передозировка»дан җан тәслим кылды. Әле дә авырга узмаганмын, дип шатлана бүген ул ханым.

Төрмәләр яшь ирләр белән тулган, күпме ир-ат ир-атларны ярата, күпмесе авыру! Ходаем, әле дә бу җиргә хатын-кыз итеп тудырмагансың дип шатланып утырырга гына кала.

Башкортстаннан бер таныш кыз белән телефоннан сөйләшәбез. Ул иптәш кызында кунакта. Телефоннан бала елаганы ишетелгәч, кем баласы, дип сорадым. Иптәш кызыныкы икән. Ире юк, аерылыштылар, диде. Авырлы чагында да бер сәбәпсезгә хатынын кыйный торган булган.

26 яшьлек бер егет белән сөйләшәм. Буе – метр да туксан. Тәскә-биткә дә чибәр генә. Акча да эшли, машинасы да бар. Яшь кызларга менә дигән кияү кебек инде. «Илфак абый, нигә ул кызлар миңа?! Миңа машинасы, фатиры, акчасы булган олырак берәр хатын кирәк. Ичмасам, рәхәтләнеп яшәп калыр идем», – ди. Озак йөрмәде, кырыклар тирәсендәге бер хатын тапты бугай ул.

Тагын бер кыз сөйли:

– Иске яңа елны бәйрәм иткәндә, ике егет иптәш кызым белән мине кафега дәштеләр. Матур гына утырдык. Тик менә официант счет китергәч боларда акча юклыгы ачыкланды. Үзем түләдем инде.

Мондыйлар белән тормыш корып буламы?! Буладыр бәлки, тик озакка түгел.

...Узган елның беренче яртысында Казанда барлыгы 4112 гаиләгә нигез салынган. Бу, алдагы елның шул вакыты белән чагыштырганда, 420 гаиләгә азрак. Икенчедән, шул ук беренче яртыеллыкта гына да 2360 пар аерылышкан. Ә бит бу яктан Казан – Идел буе округында иң яхшы күрсәткечләргә ия булган шәһәр. Россия буенча алсаң, һәр 1000 гаиләнең уртача 650се таркала. Кайбер өлкәләрдә бу сан 750гә җитә. Тарихта мондый хәлнең күзәтелгәне булмаган.

Спортзаллар, матурлык салоннары ханымнар вә туташлар белән тулган. Матуррак булсаң, кияүгә тизрәк алырлар, дип хыялланучылар болар. Ләкин бүген егетләр матурлыкка кызыкмый. Хәер, юк – кызыга, тик бер-ике кич өчен генә. «Чибәр хатын – синең хатын гына түгел ул» дигән гыйбарә ныклап кереп утырган бүгенге егетләр һәм ирләр башына. Тормыш итәр өчен алар чибәрләрне түгел, бай кызларны эзлиләр.

Бүгенгә заман туташларын чын күңелдән кызганам. Кызганам да, күпмедер горурланам да алар белән. Ялгыз булсалар да, тормышларын көйлиләр, баласын да табалар, фатирын да алалар. Хатын-кыз – ил тоткасы, дигән әйтем бүген дөреслеккә бик туры килә.

Илфак ШИҺАПОВ.

2015 елда Татарстанда беренче тапкыр Чаллының Кама балалар медицина үзәгендә бәби-бокс ачылган иде. Халык арасында бу шактый шау-шау уятты, кайберәүләр каршы чыкты, икенче берәүләр чүплекләрдә, урамнарда ташланган балалар санын киметергә ярдәм итәр дип, идеяне хуплады.

Бәби-бокста – беренче бала

Ничек кенә булмасын, моңа кадәр бәби-бокс кулланышсыз торды. Ә менә 27 гыйнвар көнне Чаллыда беренче тапкыр хастаханә янындагы тартмага бала калдырып киткәннәр. Табиблар әйтүенчә, сабый тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч янамый.

Алга таба закон нигезендә, балага «ташландык» статусы бирелә һәм ул балалар йортына җибәрелә. Анда кайбер сабыйлар яңа әти-әнисен таба. Шулай ук үз әти-әнисе дә баласын эзләп табып, кире гаиләгә кайтара ала. Дөрес, моның өчен баласын ташлаган ана, ДНК анализы тапшырып, сабыйның үзенеке икәнен дәлилләргә тиеш. Бәби-боксларны күпләр «килеп җиттек...» дип бәяләсә дә, бу очракта республикабыз өчен әлеге ят җайланма ярдәмендә баланың гомере саклап калынган.

Бәби-бокс, инглиз теленнән тәрҗемә иткәндә, «тормышка тәрәзә» дигәнне аңлата. Шулай ук аны «өмет бишеге» дип тә йөртәләр. Бу җайланмаларны, гадәттә, медицина учреждениесе бинасының урам ягына беркетәләр. Ул ачыла торган металл-пластик тәрәзәле, эчке яктан махсус карават-бишекле урын. Тыштан банкоматны хәтерләтә. 30 секундтан соң тәрәзә үзеннән-үзе бикләнә һәм аны тышкы яктан инде ачып булмый. Бәби-бокс эчендә сак та, видеокамера да юк. Медицина хезмәткәрләре бәби-бокста бала калдырылганы турында кыңгырау тавышыннан һәм лампа җемелдәп торудан беләләр.

Пошалым чаналары хуҗаларын тапты

Узган ял көннәрендә Арча районының Урта Пошалым авылында «Пошалым чаналары» фестивале гөрләде. Җыр бәйгесе җиденче тапкыр уздырыла. Баштагы елда өч Пошалым авылын берләштергән фестиваль соңгы ике елында район күләмендә уза. Быелгысында 38 кеше катнашты һәм һәркайсы өчәр җыр башкарды.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотолары

Зөһрә САДЫЙКОВА,
Арча, Урта Пошалым

– Быел фестивальнең таләпләрен бераз үзгәрттем. Катнашучылар «Әллүки» җырын акапеллага башкарырга тиеш иде. Шуңа күрәдер дә быелгы катнашучылар аеруча көчле булды, зур әзерлек белән килгәннәр. Алардан бик канәгать калдым, – диде фестивальнең хуҗасы – Татарстанның халык артисты Рөстәм Закиров.

Инде менә ничә еллар ул үзешчәннәр арасында иңиңнәрен сайлап алып, аларны үсендерә, стимул бирә. Узган еллардагы катнашучылар арасында бүгенге көндә профессиональ сәхнәдә ныклы адымнар белән иҗат итүчеләр дә бар. Мәсәлән, Илназ Бах (ул фестивальнең беренче ел лауреаты), Фәрид Низамиев, Рафил Җәләлиев һәм Сөмбел Заһидуллина – әнә шундыйлардан.

– Әлеге бәйге – үзешчән сәнгать әһелләре өчен ачык дәрес. Лауреатлар, Арчаның мәдәният йортында чыгыш ясап чирканчык алганнан соң, Казан филармониясе сәхнәсендә җырладылар. Иҗатка җитди карап, киләчәген сәхнә белән бәйләүчеләр өчен бу трамплин булып тора, – ди Рөстәм әфәнде.

Быел үзешчән җырчыларның талантын Татарстанның халык артистлары Зөһрә Сәхабиева белән Резидә Галимова, Татарстанның атказанган артисты Газинур Фарукшин, Башкортстанның танылган җырчысы Марат Шәйбәков һәм Люция Мусина бәяләде.

– Иң-иңнәрне сайлаганда бик дулкынландык. Араларында тыңлап туймаслыклары да бар. Быел бәйгенең таләпләре катгыйланган. Башкарыр өчен катлаулы җыр сайланган. Шуңа да карамастан, һәр катнашучы җырны бәйгенең шартына туры китереп башкарырга тырышты. Классик әсәрләр җырлаучылар да булды, – диде Газинур Фарукшин.

– Бик күңелле мизгелләр кичердек. Зәлия Гайфуллинаны ошаттым. Җырларны җиренә җиткереп башкарды, төс-кыфәте дә килешле, затлы. Тавышы моңлы. Катнашучылар арасында гап-гади авыл хезмәтчәннәре – сыер савучылар да, бозау караучылар да, машина йөртүчеләр дә, шулай ук өлкән яшьтәге апа-абыйлар да, мәктәп укучылары да булуы сөенделәре. Киемнәренә карата да тәнкыйть сүзләрен әйтеп булмый, – дип, хискичерешләре белән уртаклашты Резидә Галимова.

Җюри исә түбәндәгеләрне җиңүчеләр дип игълан итте: беренче урын лауреатлары – Арчадан Зәлия Гайфуллина (ул «Әллүки» җырын иң оста башкаручы дип тә билгеләнде) һәм Илһам Яруллин (Урта Аты). Икенче урынны исә Айрат Кәримуллин белән Гүзәл Закирова бүлеште. Җиңүчеләр диплом, биш-ун мең сум күләмендә акчалата премия белән бүләкләнде. Һәм барлык катнашучыларга да чаналар тапшырылды.

Хәер, фестивальне катнашучылар гына түгел, ә авыл халкы да бик сагынып, ярытып көтеп алганлыгын күреп сокландык. Сәхнә түрендә күз күрке булып торган бизәкле чаналар үзләре генә дә ни тора! Шулай ук Югары Пошалымның балта осталары ясаган арбаларны җиккән атлар – һәммәсе дә бәйрәм рухын арттырды.

– Рөстәм авылның һәр кешесенә – олысына да, кечесенә дә бик ихтирамлы. Ел саен бәйрәмнәрдә өлкәннәргә һәм балаларга бүләкләр тапшыра. Авылның һәр бала-чагасын исемләп белә, кайткан саен аларның күңелен күрергә тырыша, – ди Рөстәм Закиров турында авылдашлары.

«Фиксилар» татарча сөйләшә

Бай мәгълүматлы, нәниләр күңеленә хуш килгән «Фиксилар» мультфильмының татарчага тәрҗемә ителүе турында язган идек инде. «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында шул уңайдан матбугат конференциясе узды. Журналистлар белән очрашуга «Фиксилар» татарчалаштырылган «Аксу» продюсерлык үзәге җитәкчесе Рөстәм Сәрвәров, Татарстанның халык артисты Хәлим Җәләл, Ноликны татарча сөйләштергән Казан шәһәренең 111нче мәктәбенең 8нче сыйныф укучысы Энҗе Әхмәтҗанова килгән иде.

«Аксу» студиясенең мондый тәрҗемәләргә беренче тапкыр гына тотынуы түгел икән инде.

– Моңарчы үзебез яратып карап үскән совет мультфильмнарын тәрҗемә иттек. 2010 елдан башлап шундый 40лап мультфильмны татарчалаштырдык. Карлсон, Крокодил Гена, Винни Пух... Нигә бу юлы нәкъ менә Фиксиларга тукталдык диярсез. Бу мультфильм балаларны техниканы, хезмәтне яратырга, тырыш, эзләнүчән булырга өйрәтә, күп мәгълүмат бирә, бик игелекле, күңелле дә, – диде Рөстәм Сәрвәров, сайлауларының сәбәбен шәрехләп.

Эш шактый күп, авыр һәм катлаулы булган. Бер геройны татарча «тавышландырыр» өчен генә дә өч-дүрт кандидатны сөйләтеп караганнар. Тембрлар туры килми аптыраткан. Көнне төнгә ялгап, тәүлек буе эшләгәннәр. Бүген бу мультфильмны теләгән һәркем Татарстанның Мәгариф һәм фән министрлыгы сайтына кереп карый ала. Киләчәктә диска да чыгачак. Танылган әдипләр Роберт Миңнуллин, Разил Вәлиев, Рабит Батуллалар һәм тел белгечләреннән киңәш-табыш, фатиха алып иҗат иткәннәр. Эш Мәгариф һәм фән министрлыгы кушуы буенча, Телләрне саклау турында дәүләт программасы кысаларында башкарылган.

Тамашачы күңеленә шаянлыгы-шуклыгы, утлыгы-мутлыгы белән кереп калган артист Хәлим Җәләл өчен дә мультфильм геройларын татарча сөйләштерү яңалык түгел.

– Безгә күп кенә мультфильм геройларын турыдан-туры эфирда татарча сөйләштерергә туры килде. Ләкин, кызганыч, сыйфаты бик түбән иде, – диде ул. Киләчәккә хезмәт итә алганы өчен сөенечен дә яшермәде. – Балалар өчен эшләү – иң изге гамәл. Моның өчен акчаны санап кызганып торырга кирәкми, – диде сәхнә ветераны.

«Фиксилар»да Ноликны татарча сөйләштергән Энҗе Әхмәтҗанова да үзләренең бик кирәкле һәм файдалы эш башкаруларын аңлап эшләгән. Аның алты яшьлек энекәше, гаилә кануннары бозып, күбрәк рус теленд сөйләшә икән.

– Моның сәбәбе – энемнең мультфильмнар яратуында. Бакчадан кайтуга, телевизорны кабыза. Ләкин «Карусель»дә дә, «Дисней»да да бары тик рус телле мультфильмнар гына. Минем тавышым белән сөйләшкән бу татарча мультфильм энемә бик ошады, кат-кат карады, бернечә сүз булса да татарча да өйрәнде. Башка балаларны да безнең «Фиксилар» туган телгә өйрәтсәләр, әйбәт булыр иде, – диде Энҗе Әхмәтҗанова.

Аның үзе өчен дә сәхнә ят әйбер түгел. Ул инде күп кенә телевизион спектакльләрдә уйнап, тамашачы күңелен яулады.

– Мин Ноликны бик яраттым, ул миңа охшаган – үзе кечкенә, үзе тиктормас, – дип, журналистларны елмайтты Энҗе.

Тәрҗемә итү шактый чыгымнар сораса да, яңа мультфильм тудыру тагын да кыйммәткәрәк төшә. «Бүген тотынып татарча мультфильм эшли алмыйбыз әле. Кызыклы текстлар да, сценарий авторлары да юк. Ләкин киләчәктә бу башкарып чыкмаслык эш түгел, – диде Рөстәм Сәрвәров. – Балалар ярата карый торган «Смешарики» мультфильмының авторы – Түбән Камадан татар егете. Менә шундый талантларны кызыксындырып үзебездә эшләтә алсак, татарча мультфильмнарыбыз да булыр».

Йолдыз ШӘРАПОВА.

Җир астында йөрү җайлырак

Казанда узган ел электр транспортыннан 66,9 миллион кеше файдаланган, шуның 27 миллионы – метрода йөрүчеләр.

Дамир Бәдриев фотосы

Хәзер Казан метрополитенының беренче линиясенең ун станциясе эшли. Икенче линиягә күчену ролен үтәячәк «Имәнлек» («Дубравная») станциясе төзелеше бара. Узган ел метро станцияләренә юл йөрү билетлары сата торган автоматлар куелды, түләүне банк картасы аша да башкарырга була. Нәтиҗәдә кассаларда чират тору «элеккеге заман күренеше» рәвешендә тарихта калды.

– Ил автосәнәгатенә теләктәшлек программасы уңышлы гына гамәлгә ашырыла барган очракта, быел шәһәргә яңа 15 яңа троллейбус һәм 7 яңа трамвай сатып алыначак, – дип хәбәр итте «Метроэлектротранс» муниципаль унитар предприятиесе генераль директоры Әсфән Галәвов «эшлекле дүшәмбе» киңәшмәсендә.

Казанның электр транспорты паркын яңарту 2007 елдан башланды. Узган ел гына да 70 яңа троллейбус һәм 22 яңа трамвай кайтартылды, ике километр трамвай юлы төзекләндерелде.

– Трамвайлар, троллейбуслар уңайлы хәзер. Салоннар җылы, физик мөмкинлекләре чикле кешеләр өчен идәннәр тәбәнәк итеп ясалган, күперчек, ягъни аппарель көйләнелгән, – диде Әсфән Галәвов.

Трамвайларда, троллейбусларда һәм автобусларда да идәннәрне тәбәнәк итеп ясау үзе яңа проблема тудырды. Баскычлы идән пассажирларның егылуына этәрә. Юл хәрәкәтендә җәмәгать транспортына өстенлек бирмәү кайчак авария белән тәмамлана.

«Казан-1» тимер юл вокзалы белән «Кояшлы шәһәр» торак комплексын ялгаучы 5нче маршрут быел тагын бер өч секцияле трамвайга артачак. Әлеге трамвайны сатып алу килешү нигезендә расланган инде.

Мэр Илсур Метшин «Метроэлектротранс» предприятиесенең Казан белән берррәттән үсештә булуын ассызыклады.

– «Метроэлектротранс» – башкаланың үрнәк предприятиесе. Яхшы эшлиләр, матур традицияләрне саклап калдылар, коллективны кайгырталар, – диде Илсур Метшин.

«Метроэлектротранс» предприятиесе дирекциясе башлангычында, күпмилләтле коллективта һөнәри осталык конкурслары, спартакиадалар, үзешчән сәнгать фестивальләре даими үткәрелеп тора.

Рәдиф КАРАГАЙ.

Акча үзләштерсәң, эзеңә тиз басачаклар

Предприятие һәм оешма җитәкчеләре, шулай ук дәүләт һәм муниципаль органнар хезмәткәрләре дәүләт заказлары буенча эшчәнлекләрендә финанс кагыйдәләрен бозсалар, административ җаваплылыкка тартылачаклар, җинаять эше дә кузгатылырга мөмкин.

Татарстан премьер-министры Илдар Халиков бу кисәтүне Республиканың сатып алулар буенча дәүләт комитеты коллегиясе утырышында ясады. Республиканың юстиция министры Лариса Глухова да законнарның катгый үтәлергә тиешлеген искәртте.

Бөтенроссия халык фронтының Татарстан төбәк бүлеге штабы рәистәше Игорь Бикеев үзенең чыгышында республикада узган ел дәүләт заказларына бәйле 100 шикле очрак ачыкланганлыгын әйтеп үтте.

– Россия Президенты Владимир Путин дәүләт заказлары буенча эшчәнлектә законнарны бозмаска чакырды. Бөтенроссия халык фронты да дәүләт заказларының дөрес башкарылуын күзәтчелектә тота. Татарстанда кайбер җитәкчеләр чамадан тыш кыйммәтле җиһазлар сатып алалар. Мәсәлән, иске «Тойота» автомобилен сатып алуга дүрт миллион сум күчерелгән. Әлеге машинаның яңасы да биш миллион сумнан аз гына кыйммәтрәк. Балалар бакчасы өчен сатып алу заказында кисель бәясе бер мең сум итеп куелган, ә чынлыктагы бәясе бик күпкә арзан, – диде Игорь Бикеев. – «Казан» гаилә үзәге территориясен төзекләндерүдә дә чыгымнар нормадан артып киткән.

Биектау муниципаль районы башлыгы Рөстәм Кәлимуллин сөйләгәнчә, Казан шәһәре социаль тукландыру департаменты белән дәүләт заказы нигезендә эшчәнлек районга бер ел эчендә бер миллион сумнан артык экономия ясаган.

– Ун балалар бакчасына ризык Казаннан үзәкләштерелгән тәртиптә китерелә. Меню ун көн саен яңартыла, чисталык тәэмин ителгән. Районыбыздагы мәктәпләрдә дә туклandыруны Казан шәһәре социаль тукландыру департаменты аша оештырырга ниятлибез, – диде Рөстәм Кәлимуллин.

Республиканың сатып алулар буенча дәүләт комитеты аша узган ел 313,3 миллиард сумлык сатып алулар башкарылган.

– Татарстанда товарлар сатып алу, эшләр башкару һәм хезмәт күрсәтүләр өлкәсенә кагылышлы «Төбәк мәгълүмат системасы» эшли. Анда «шәхси кабинет» теркәргә була, сатып алулар турында белешмәләр белән танышып торырга уңайлы ул. Россиядә беренче булып, республикада 2016 елда сатып алуларда электрон документ әйләнеше алымы гамәлгә куелды, – дип әйтеп үтте үзенең докладында Республика сатып алулар буенча дәүләт комитеты рәисе Ольга Редько.

Премьер-министр Илдар Халиков комитетның узган елдагы эшчәнлегенә уңай бәя бирде.

– Дәүләт ихтыяҗларына заказлар кабул иткәндә «бу безнең кеше», «монысы чит кеше», «атказанган» дигән бәяләмә юк. Сатып алуларда һәркем тигез булсын, дәүләт акчасы төгәл файдаланылсын, – диде Илдар Халиков.

Дәүләт заказлары, ягъни сатып-алулар өлкәсен җәмәгатьчелек күзәтчелегендә тотканнары, закон бозучыларны фаш иткәннәре өчен, премьер-министр массакүләм мәгълүмат чараларын да рәхмәт белән телгә алды.

ХӘРӘКӘТ ИМИНЛЕГЕ

Без әле һаман кырылабыз

Татарстанда узган ел 5039 юл-транспорт һәлакәтендә 450 кешенең гомере өзелде.

Бу коточкыч санны республиканың ЮХИДИ идарәсе җитәкчесе Ленар Габдерахманов юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча хөкүмәт комиссиясе утырышында әйтте.

– Узган ел 17 муниципаль районда юл-транспорт һәлакәтләре нык артты. Кышкы чорда юлларның каралмавы аварияләр чыгуга этәрә. Азнакай һәм Кукмара районнарында кышкы чорда юлларны карау эшенә килешү әле һаман кабул ителмәгән. Теләче һәм Яшел Үзән районнары үзләрендә юл иминлеген тәэмин итү чараларына акча гомумән дә күчермәгән. Муниципаль районнардагы юл хәрәкәте иминлеге комиссияләре юньләп эшләми, – дип тәнкыйтьләде Ленар Габдерахманов.

Республика торак пунктларында юллар аша ясалган 6469 кичүнең 2380е норматив таләпләргә җавап бирми. Хәер, узган ел 1200 кичү төзекләндерелгән.

– Җәяүле юл кичүләренә битараф калырга ярамый. Транспорт чараларын идарә итүчеләр юл кичүләрендә 656 кешене бәрдерде, 23 кешене үтерде, – дип кисәтте республиканың баш автоинспекторы. – Аварияләрнең күбесенә тизлекне сакламау сәбәпче.

Горький тимер юлының Казан төбәге буенча урынбасары Александр Черемнов сөйләгәнчә, узган ел республикадагы тимер юл кичүләрендә 12 авария теркәлгән, бер кеше үлгән.

– Чит кешеләр тимер юл хуҗалыгына кермәсеннәр, тимер юл өстендә йөрмәсеннәр иде. Тимер юл хуҗалыгына катнашы булмаган 52 кеше имгәнү алды, 31 кешенең гомере өзелде, – дип искәртте Александр Черемнов.

Татарстан буенча юлларның 173 участогы аеруча хәвефле санала, аларда аварияләр еш килеп чыга. Республиканың транспорт һәм юл хуҗалыгы министры Ленар Сафин сүзләренә караганда, юлларның хәвефле участокларын үзгәртеп төзекләндерү өчен муниципаль берәмлекләргә беркадәр акча күчереләчәк. Ләкин экономияләнгән финанс чыганаклары барлык хәвефле участокларга да җитмәячәк. Шунлыктан транспорт чарасында юлларның кискен борылышлы урыннарын «җәяүле адымы» тизлегендә генә узуың мең кат хәерлерәк булачак.

Татарстан премьер-министры урынбасары – Министрлар кабинеты аппараты җитәкчесе, юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча республика хөкүмәте комиссиясе рәисе урынбасары Шамил Гафаров муниципаль берәмлекләрдәге юл хәрәкәте иминлеге комиссияләренә кыска вакыт эчендә эш планнарын булдырырга күрсәтмә бирде.

– Узган ел үлүчеләр саны аннан элеккеге ел белән чагыштырганда азрак булды, ләкин аварияләр саны артты. Аварияләр саны арта икән, димәк, үлүчеләр саны да, һичшиксез, артачак, – дип, юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү чараларына җаваплы кararга чакырды Шамил Гафаров.

Татарстан узган елгы юл-транспорт аварияләре саны буенча Россия күләмендәге «кара исемлектә» дүртенче урында тора.

Дамир БӘДРИЕВ.

Автор фотолары

Яшь ветеринарлар йортлы булды

Кече Елга авылының Тынычлык урамында үзенчәлекле ветеринария үзәге пәйда булды. Маллар дәвалаучы участок табибы пунктыннан тыш биредә әле яңа торак йорт та салып куйганнар. Анда мал табибы булып эшләүче Айгөл белән Илнур Нәбиуллиннар гаиләсе яши.

Алисә САБИРОВА,
Лаеш, Кече Елга

Йорт Лаеш районы хакимияте һәм ветеринария идарәсе ярдәмендә салынган. Яшьләр бары коммуналь хезмәтләр өчен генә түләячәк.

Илнур белән Айгөл Бауман исемендәге Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясендә таныша. Икесе бер курста белем ала. 2006 елда уку йортын тәмамлыйлар, ләкин яшь гаилә авылга кайтырга ашыкмый әле. Башта Казанда үз көчләрен сынап карарга булалар. Илнур төзелеш өлкәсендә эшли. 2008 елгы кризис аларның оешмасына да тәэсир итә.

– Дөресен әйткәндә, авылга чарасызлыктан кайттык. Ләкин үкенмибез. Тормыш иптәшем – шәһәр кызы. Ул да, балаларны авылда үстерү кулайрак, ди. 2011 елдан икебез дә районда мал табибы булып эшли башладык. Миңа эшем бик ошый. Авылыбыз Казаннан ерак түгел, тиз генә барып килергә була. Хезмәт хакы 25 мең сум, шуңа өстәп, премия дә бирәләр әле. Айныкын-айга алып барабыз. Эш белән өйнең янәшә булуы да кулай, ашыгыч рәвештә берәр авылга чакырырга мөмкиннәр, дарулар да, инструментлар да янда гына, – ди Илнур.

Яшь гаиләнең өч баласы бар: төпчекләренә әле ике генә яшь булса, олысы инде дүртенче сыйныфта укый.

Хәзерге вакытта районда өч ветеринария пункты эшли. Авылда сыер асраучылар да күбәеп киткән. Илнур Нәбиуллин карамагында гына да өч меңгә якын мөгезле эре терлек, 500 сарык, кәҗә.

Малларны дәвалау пункты бинасында исә участок табибы кабинеты, дарухәнә, маллар карау өчен аерым бүлмә, ясалма орлыкландыру пункты урнашкан. Лаеш районы башлыгы Михаил Афанасьев сүзләренчә, ветеринария пункты төзү өчен әлеге урын очраклы гына сайланмаган.

Ветеринария пункты юл кырыенда төзелгән, бу исә авыл халкы гына түгел, ә башка торак пунктлардан да мал табибына мөрәҗәгать итә алалар дигән сүз. Якын арада биредә мал-туар өчен кирәк-ярак туплаган кибет ачарга уйлыйбыз. Әлегә бу – пилот проект. Аның нәтиҗәсен күрсәк, башка авылларда да шундый үзәк булдырачакбыз. Мал табиблары бик кирәк, – диде Михаил Афанасьев.

Белгечләргә кытлык булуы хакында Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясе ректоры Рөстәм Равилов та әйтеп китте.

– Ерак районнарда әле хәзер дә мал табиблары җитми. Бу – без белгечләр әзерләмибез дигән сүз түгел. Яшьләрнең авылда төпләнәсе килми. Эше пычрак, тәүлекнең теләсә кайсы вакытында чакыралар. Дөрес, хәзерге вакытта яшьләргә күтәрелеп китү өчен дәүләт ярдәм күрсәтә. Хезмәт хакына өстәмәләр бар, торак белән тәэмин итү өчен субсидияләр каралган. Татарстанда соңгы арада йөзгә якын яшь мал табибы һәм зооинженер эшкә урнашты. Мал табибларына ярдәм кулы суза торган мондый программалар әле Россиянең бер төбәгендә дә юк, – диде ректор.

Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының Баш ветеринария идарәсе җитәкчесе, республиканың баш дәүләт ветеринария инспекторы Алмаз Хисаметдинов сүзләренчә, соңгы ун елда участок мал табиблары өчен бер генә дә торак йорт төзелгәне булмаган.

– Мондый пунктлар үсү өчен мөмкинлеге булган, ләкин белгечләр җитмәгән авылларда төзелә. Берничә ел элек биредә бушлык иде. Президент программасы ярдәмендә, республика буенча 126 ветеринар пункты төзедек. Район башлыгы белән киңәшләшкәннән соң, яшь белгечләрне җәлеп итү максатыннан, биредә йорт та салып куярга булдык. Алга таба бу проектны дәвам итәчәкбез, – диде Алмаз Хисаметдинов.

«Әле дә син бар, Диләфрүз!»

Мәскәүдә эшләп килүче «Диләфрүз» халык театры, 30 еллык юбилее уңаеннан, Казанда тамашачы хозурына концерт программасын, спектакльләрдән өзекләр тәкъдим итте.

Люция ХӘБИБУЛЛИНА

«Мәскәү халкын сәнгатькә борырга тырышып, дер селкетеп торучы әле дә син бар, Диләфрүз! Барлык татар оешмаларының кулыннан килмәгән эшне җирәнә җиткереп башкарасың». Әлеге юлларны Мәскәүдә яшәп иҗат итүче язучы Нәзифә Кәримова язган. Моннан өч дистә ел элек Диләфрүз Дежурова оештырган театр репертуарында нинди генә спектакльләр юк. Туфан Миңнуллин, Фәнис Яруллин, Мирхәйдәр Фәйзи әсәрләрен бик яратып куялар. Россиянең төрле төбәкләренә гастрольләргә йөреп торалар. Мәскәүдә узган Милли театрлар фестивалендә лауреат исемен яулаганнар. Көн кадагына туры килердәй скетчларын Диләфрүз ханым үзе яза. Аның кызы Гөлнара да яшьтән шушы театрда уйнаган. Оныгы Рената да театрдан аерылмый. Театр каршында балалар студиясе ачып җибәргәннәр.

Төрле проблемалар булуга карамастан, Диләфрүз Дежурова театрны яшәтергә омтыла. Кая гына барсалар да, автобуслары булмагач, декорацияләре дә, музыка җиһазлары да үз иңнәрендә. Коллективта 20 кеше. Аларның һәркайсы таланты белән аерылып тора. Араларында халыкара җыр конкурслары лауреатлары бар. Кайберләрен профессиональ җырчылардан аерып та булмый. Зиннур Аляутдинов алдан ук фонограммасыз гына җырлавын әйтеп куйды. Ул Мәскәүдә татар яшьләрен кавыштырып та изге эш башкара. Таныштыру кичәләре оештыра.

Фәйрүзә Кәримуллина оста итеп спектакльдә уйнавы белән дә, җырлавы белән дә җәлеп итте. «Шушы театрга йөреп, рухи азык алам», – ди ул. Диләфрүз ханым белән очраштырган өчен, язмышына рәхмәтле Фәйрүзә. Тумышы белән Балык Бистәсе районының Югары Тегермәнлек авылыннан.

Марс Гарипов әлеге театрга ундүрт ел элек килгән. Гомеренең 60 елын педагоглык хезмәтенә багышлаган. Ә театр белән кызыксынуы бала чагында туган ягы Азнакай төбәгендә башланган. 80 яшенә җиткән Марс әфәнде бернинди уен коралыннан башка «Кара урман»ны моңлы итеп җырлавы белән сокландырды.

Араларында иң яше Айдар Даутов булгандыр, мөгаен. Аны театр өчен яратылган, диярсең. Әнисе Айсылу ханым үз улын сәхнәдә күрәсе килсә дә, егет стилист һөнәрен сайлаган. Концертта чыгыш ясаган һәр җырчыга киемнәрне, аларның төсләрен зәвыклы итеп сайлауда ярдәм иткән Айдар. Катнашучылардан Рафыйк Вәлитов, Зөлфия Хәлилова, Хәмисә Хөсәенова һәм башкаларның чыгышлары тамашачыда җылы тәэсирләр калдырды. Театр турында чыккан китаплары да әлеге концерт-тамашада тәкъдим ителде.

Наилә ГӘРӘЕВА, Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты:

– Мәскәүдә театр тоту җиңел түгел. Анда элек тә театр бар иде. Диләфрүз аны күтәреп алды, чөнки милләтебезне театр саклый. Һәркайсы башка һөнәр иясе булуга карамастан, артистлар бик оста уйныйлар, җырлыйлар, – диде ул.

«Дакар» көчлеләр өчен

Татарстан пилотлары бу юлы да сынатмады: быел «КАМАЗ-мастер» экипажы – «Дакар» раллисында кабат җиңүче пьедесталында. Шул ук вакытта Африкада барган «Африка-ЭкоРейс» ярышларында да безнекеләр алдынгы булды.

– Бу ике ярыш та бик җитди иде, командадан күп көч таләп итте. Берәүнең дә җиңүне җиңел генә бирәсе килми. Беренче урынга 15 экипаж дәгъва кылды. Һәр минут, һәр метр өчен ярыштык. Көндәшләребез белән аерма нибары 2,5 минут кына иде, – диде «КАМАЗ-мастер» командасы җитәкчесе Владимир Чагин.

«Дакар – 2017» раллисы җиңүчесе Эдуард Николаев җиңүнең чын мәгънәсендә яулап алынганлыгына тукталды.

– Аеруча һава торышы сынады. Оештыручылар корылык вәгъдә иткән иде, ләкин берничә көн тоташ яңгыр яуды. Шуның аркасында махсус әзерләнгән мәйданчыклардан баш тартырга туры килде. Йөк машиналарына икеләтә авыр булды. «КАМАЗ»лар җир астына төшеп кенә китте. Аларны трактор, экскалатор белән чыгарырга туры килде. Сак йөрергә тырышсак та, без дә чокырларга эләктек, ләкин көндәшләребезгә караганда тизрәк чыктык. Әллә ничә тапкыр көпчәкләр тишелде. Көньяк Америкада тимерчыбык кебек үлән үсә, көпчәкне менә шул ертып-ертып ала. Ничек тә туктамаска тырыштык. Көпчәк алыштыруда 8-12 минут вакытны ала бит, – диде Эдуард Николаев.

«Дакар» раллисында быел беренче тапкыр Россия командасы багги классында (җиңел машиналар ярышы) җиңү яулады. Равил Маганов белән Кирилл Шубин, раллида тәүге тапкыр катнашып, өченче урын алды. Хәзер егетләр «Ефәк юл» ярышларына әзерләнә.

Спортчылар сүзләренчә, җиңү өчен машина гына түгел, ә кеше дә физик яктан әзерлекле булырга тиеш. Таулы җирдә узышканда аеруча.

– Тауларда ун метр җәяү барсаң да авыр: игътибар кими, баш авырта, күңел болгана. Автомобиль спортында уңыш 50 процент – машинадан, 50 процент кешедән тора. Кайвакыт тыштан көчле булып күренгән ир 50-100 чакрымнан соң коелып төшә, – диде күпне күргән Владимир Чагин.

«Дакар» раллисында техник регламент һәрвакыт үзгәреп тора. Бу, әлбәттә, «КАМАЗ» өчен файдага түгел. Мәсәлән, 2018 елда булачак ярышларда двигательнең ягулык сыйдырышлыгы 13 литрдан артмаска тиеш, ә «КАМАЗ»ныкы – 16,2 литр.

– Хәзерге вакытта двигательне үзгәртү буенча эш алып барыла, ләкин киләсе елга катнашу-катнашмау мәсьәләсе ачык кала, – диде Владимир Чагин.

2011 елда спорттан киткән тере легенда рульне яшьләргә тапшырганнан соң булган кичерешләре белән дә уртаклашты.

– Спорттан киткәч, рульгә бүтән утырмадым. Күбрәк янәшә утырып йөреп, яшьләргә киңәшләр бирдем. Хәзер аларның җиңүләренә үземнекенә караганда да ныграк сөенәм. Без Татарстаннан булуыбыз белән горурланабыз. Элек чит илләрдә «КАМАЗ» сүзен дә көчкә әйтәләр иде, хәзер «КАМАЗ»ны да, Татарстанны да беләләр, – диде Владимир Чагин.

Алисә САБИРОВА.

ТОРМЫШ КЫЙПЫЛЧЫКЛАРЫ

Акча

Базар каршындагы тукталышта бер абзый гармун уйный. Алдында катыргы тартма – үткән-сүткән шунда вак акча ыргыта. Җиде-сигез яшьлек малай әтисенең җиңеннән тарта. «Әти, бир әле акча». Тегесе: «Нигә ул сиңа?» – ди. «Әнә теге абыйга бирәм». Ата кеше нидер уйлап алды да: «Әнә үзеңә биргән акчаңны сал!» – дип куйды. Хәзер инде малай уйга калды. Гармун уйнаучыга хәер дә бирәсе килә, үз акчасы да кызганыч. Ләкин миһербанлык җиңде – малайның сагызгамы, туңдырмагамы дигән акчасы, чылтырап, тартмага барып төште...

...Даими рәвештә педагогик эксперимент үткәрергә ярата торган танышым сөйли: «Каяндыр укыдым да болай эшләргә булдым. Хәзер малайга һәр нәрсә өчен акча түлим: идән юа – 10 сум, савыт-саба юа – 10 сум, «биш»ле ала – 10 сум, кибеткә барып кайта – 15 сум. Башта эш шәп барды: без кайтканчы, өйләр дә җыештырылган, укуында да алга китеш, әле тагын нәрсә эшлим дип кенә тора. Бермәлне акча бетеп китте. Малайга: «Син язып бар, аннары түләрбез», – дип тә карыйм – юк, ризалашмый. Барып чыкмады эксперимент. Хәзер психологлар, педагоглар, баланың үзенең кесә акчасы булырга тиеш, шул чакта ул үзен ышанычлырак хис итә, диләр. Шулайдыр, заманасы шул бит, үзен кеше итеп тояр өчен, балага да акча кирәктер. Ләкин болай гына акча бирел тә, яхшы билгене «сатып алып» та, баланы кем итеп тәрбияләрбез икән соң без?

Моннан берничә еллар элек инде, «шабашка»да эшләгәндә, безгә ярдәмчеләр кирәк булды. Болай да гел безнең янда буталып йөргән 12-13 яшьлек малайларның икесен сайлап алдык та, көненә 70 сум түләп, эшкә яллادык. Эшләре күп килерлек булмаса да җиңел түгел, билгеле, ләкин хезмәт хакын да ике көнгә бер түлибез. Малайларыбызның тазарак дигәне беренче ике көн өчен акчаны алды да, бүтән күренмәде. Икенчесе исә җәй буе безнең белән эшләде, әле көз көне укудан соң да килеп йөрде. Иң кызыгы – көзгә таба безнең янга саллы гына киенгән бер ир килде, җәй буе эшләгән малайның атасы икән. Үзе Себердә эшли. Әзрәк сөйләшеп утыргач, ул безне шаккатырды. «Малайга акчаны мин болай да бирәм анысы, – диде ул. – Тик үзе эшләп алганы тәмлерәк тоелган аңа, киләсе елга да эшлим дип тора. Менә ялга кайткач, сезнең белән ничә сум эшләгәнен белдем дә нәкъ шуның кадәр үзем дә өстәдем. Иртәгә компьютер алабыз».

Шунысы кызык, ул малай бер тапкыр да үзенең акчалы гаиләдән икәнен сиздермәде. Урамнан үткән әби-чәби: «Улым, нигә азапланасың?» – дия башласа, тизрәк алардан «таю» ягын карый иде ул...

Без кечкенә чакта, җәйге каникулга чыккач, колхоз бригадирына барып ялына идек. Ул бераләр эш табып бирсә, түбәбез күккә тия иде. Юк, акча кирәктән түгел, «үз» акчаң кирәктән иде ул.

Бүген без, барлы-юклы 15-20 ел эчендә илебездә рухи дөнья җимерелеп, бөтен нәрсәнең акчага бәйлелегеннән зарланабыз. Ләкин җәмгыятьнең күпчелеген әле акчаның кадерсезрәк чагында тәрбияләнгән буын тәшкил итә. Ә теләсә ничек акча эшләргә өйрәнеп үскән, шуны төп максат итеп куйган буын килгәч, ни булыр? Хәер, озак калмады, күрербез, насыйп итсә. Тик картлар йортына чиратка бүген үк басу хәерлерәк булыр кебек... Чөнки бүгеннән акчага яратырга, акчага булышырга, акчага яшәргә өйрәнеп үскән буын безне бушка карар дип кем әйтә ала?..

Илфак ШИҺАПОВ.

Шәһри КАЗАН

ИНДЕКСЛАР
П2395 (3 тапкыр чыга)
П2430 (пәнҗешәмбе саны)
П2419 (оешмалар өчен)

www.shahrikazan.com

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ (НӘШЕР ИТҮЧЕ) – «ТАТМЕДИА» АҖ
«ТАТМЕДИА» АҖ ФИЛИАЛЫ ҖИТӘКЧЕСЕ –
БАШ МӨХӘРРИР ГӨЛНАРА ИЛЬЯС кызы САБИРОВА.
ЧЫГАРЫЛЫШ ӨЧЕН ҖАВАПЛЫ – РАСИХА ГАБДЕЛБӘР кызы ИСМӘГЫЙЛОВА.
© Газетада басылган язмаларны файдалану, шулай ук өзекләр китерү өчен, «ШК» редакциясеннән язмача рөхсәт алу мәҗбүри. Редакциянең фикере авторларның фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин. Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк. Кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Реклама һәм игъланнардагы мәгълүматларның дөреслеге өчен аны бирүчеләр үзләре җаваплы.
РЕКЛАМА ХЕЗМӘТЕ
Тел: (843) 562-50-12,

ХАТЛАР БҮЛЕГЕ
Тел: (843) 562-50-03,
E-mail: shahri-kazan@tatmedia.com

Бу санның тиражы – 1551. Гомуми тираж – 5687.
Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
Заказ 670. Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәттә (Роскомнадзор) 2012 елның 27 августында ПИ №ФС77– 50970 нче теркәлү таныклыгы алды. Газета атнага 3 тапкыр – сишәмбе, пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә чыга. График буенча бу санга 17 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 17 сәгатьтә.

НӘШРИЯТ
«Татмедиа» АҖ
420097, Казан, Академия ур., 2

16+

Сатудагы бәясе ирекле

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ
420066, Казан,
Чистай ур., 5 нче йорт
Тел.: (843) 562-50-12,
факс: (843) 562-50-07

БАСМАХАНӘ
420066, Казан, Декабристлар ур., 2 нче йорт.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы.
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы